# Әфган – әниләрнең йөрәк ярасы

Чираттагы изге эшләр тукталышын без “Әфган – әниләрнең йөрәк ярасы ” дип атадык.

2014 нче елның декабрь ахырында Советлар Союзының Әфганстанга гаскәрләр кертүенә 35 ел тула. Әфган сугышында Чаллы һәм Тукай районнарыннан 33сугышчы һәлак була. Шуларның берсе Валерий Дмитриев – безнең 2 мәктәп укучысы. Тигезсез бәрелештә ул үзенең дүрт иптәшен коткара, тик үзе дошман ядрәсеннән һәлак була. Батырлыгы өчен В. Дмитриев “Кызыл йолдыз” ордены белән бүләкләнә. Без иптәшләре хакына үз гомерен дә кызганмаган укучыбыз белән һәрвакыт горурланабыз. Әнисе Бобрук Е.И. исән вакытта аның белән аралашып тордык. Мәктәптә әфганчыларга багышланган чаралар еш оештырыла.

Әфганстанда һәлак булган сугышчыларыбызне искә алу чарасын быел “Әфган – әниләрнең йөрәк ярасы” дип атадык һәм очрашуга һәлак булган әфганчыларның әниләрен чакырдык. Хәтер көнен 1 нче Постта оештырдык. Монда Әфган һәм башка сугышларда һәлак булган солдатлар турында бай материал тупланган. Хакимова Роза Рафаэль кызы җитәкчелегендә коллектив укучыларга патриотик тәрбия бирү буенча зур эш алып барыла.

Әфганчы аналары советы рәисе Курочкина Валентина Александровна очрашуга сугыштан кайтмаган сугышчыларның зурайтылган фотоларын алып килгән.Ул улы Вячеслав һәм аның батырлыгы,үкенечле үлеме турында сөйләде. Быкова Анастасия Николаевнаның улы Юрий Быков иң беренчеләрдән булып Әфганстанга кертелә, сугышның бөтен мәхшәрен үзе аша үткәрә. Тик аңа да исән – сау әйләнеп кайту насыйп булмый. Һәр ике егет тә әти-әниләрен борчырга теләмичә, хатларында сугыш турында язмыйлар. Без әниләрнең чыгышын күз яшьләре аша тыңладык.Үзебез дә В. Дмитриев һәм башка әфганчыларның гыйбрәтле язмышлары турында сөйләдек. Очрашуның ахырында без Мәңгелек ут янына чыктык. Һәйкәл – комплекстагы мәрмәр плитәләргә әфганчыларның исемнәре чокып язылган. Сугышчыларны хөрмәт белән искә алып, без һәйкәлгә чәчәкләр салдык, әниләргә чәчәк букетлары бүләк иттек.

Без, 2 нче гимназиянең “ Ал җилкәннәр” тимурчылары, ихластан эшләнгән изге эшләребезне алга таба да дәвам итәргә уйлыйбыз. Әфганстанда һәлак булган сугышчы аналарының, якыннарының адресларын булдырдык. Аларны алдагы бәйрәмнәр белән котларга булдык.

Харисова Э.М., тимур отряды җитәкчесе


17.12.2014 12:25


17.12.2014 12:23


Нам завещаны память и слава!
Государственные символы нашей Родины
Флаг, эмблема, гимн Поста № 1
Обращение


Флаг, эмблема, гимн Поста № 1


Кодекс постовца




17.12.2014 12:20


17.12.2014 12:24